**Республика Татарстан**
**Совет Чукмарлинского**
**сельского поселения**
**Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Чукмарлы авыл җирлеге**
**советы**

РЕШЕНИЕ

КАРАР

31 июль 2019 ел

Чукмарлы авылы

№ 12

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августында 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль законы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә, Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советы карар итте:

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Чукмарлы авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августында 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1 нче кушымтаның 7 булегенең 3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәүне раслаучы документ;".

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Чукмарлы авыл җирлеге Советы рәисе: И.Х.Хадиуллин